Culture, Personality and Education
Мәдәният, шәхес һәм мәгариф
Культура, личность и образование

DOI: 10.26907/2311-2042-2024-23-2-104-116

# THE IMAGE OF KHALIULLAH THE CALIPH IN POPULAR MEMORY (FOLLOWING THE ETHNOGRAPHIC EXPEDITION OF 1991)

**Masguda Islamovna Shamsetdinova,**
USA, Seattle,
masguda@mail.ru.

The article analyses the materials, collected during the expedition in 1991, about aksakal Khaliullah the Caliph from the village of Tatarskaya Kargala. Khaliullah Gazizovich Dautov (1872–1960) was the ninth imam of the 8th Mosque in Kargala. People remember him as a saint. The informants described him as a unique healer and doctor. The documents, preserved in the archive, provide interesting facts confirming that Kh. K. Dautov was a well-educated man known far beyond the Orenburg Region, even visitors from Moscow and from abroad came to seek his help.

**Key words**: Kazan Conservatory, Tatar folk art, Orenburg Region, Kargala, scientific expedition

## Introduction

In 1991, a group of students from the Kazan Conservatory (led by Masguda Shamsutdinova) collected samples of folk music in Tatarskaya Kargala, the Orenburg Region. Part of the expedition materials was published by E. M. Smirnova [1].

Keen interest in folklore and oral literature of our people, living in this region, was sparked exactly 63 years ago. “The very first folklore expedition of the G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art to the areas, inhabited by the Tatars of Orenburg, was organized in May–June 1960, it was guided by Doctor of Philology Khamit Yarmi, a famous folklorist. The following scholars participated in the expedition: Kh. Yarmi, Kh. Gatina and Kh. Gardanov. The folklorists, divided into two groups, visited eleven villages of seven districts (the villages of Mustafino, Sarmanaevo, Novomusino of the Sharlyk District, the villages of Tukaevo and Sultakaevo of the Alexandrovskiy District, Bikkulovo of the Oktyabrskiy District, the village of Kargala of the Sakmarsky District, Radutovo and Ablyazovo of the Saryktash District, the village of Linevka of the Sol-Tyubinsky District, the village of Ozerki of the Ilek District). If we look at their expedition reports, we will find recorded: a total of 36 fairy tales, 2530 short songs, 32 ballads, 27 bayts, 215 proverbs and riddles, 12 folk games, 64 anecdotes, 28 chants and 18 memories. Thus, within a month, the institute’s staff collected valuable folk art material for research” [2, p. 3]. Some of the findings, collected in this region, were published in a twelve-volume collection of Tatar folk art prepared by the Institute (1975–1988) [3].

To study the subdialects of the Orenburg Tatars, dialectologists repeatedly went on expeditions to this region. The Orenburg Tatars' dialects were studied monographically [4], [5]. The dialects, widespread in the region, are presented in the "Atlas of Tatar Folk Subdialects" [6].

In 2015, a group of researchers from G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art went to the Orenburg Region to collect folk gems, the head of the complex scientific expedition was I. Yamaltdinov. They published a book containing the spiritual treasures of this region [4, p. 2].

## Methodological basis of work

The research materials include interviews with the informants from the village of Tatarskaya Kargala, the Orenburg Region, recorded in 1991 [7]. The methodological basis of the research is the ideographic (descriptive), retrospective and historical comparative methods.

## Discussion



*The image of Khaliullah the Caliph (Khaliullah Gazizovich Dautov, 1872–1960)* [8, p. 57]

Khaliullah Gazizovich Dautov (1872–1960) was the ninth imam of the 8th mosque in Kargala. In his research work, historian K. A. Morgunov provides the following information about this outstanding personality: "He was born in 1872 in the village of Kargala, where he graduated from a madrasah in 1894" [9, p. 80]. His mentor was Khairulla Ishan, the mullah of the First Kargala Mosque [10, p. 374].

In 1894–1910, he served in the 23rd Kozlovskiy Infantry Regiment, stationed first in Kursk and then in Kharkov. After demobilization, Kh. G. Dautov worked as a teacher in a madrasah in the village of Kargala for ten years, from 1910 to 1920 [9, p. 80]. In 1930, he was threatened with arrest. During a search, the imam's personal documents and liturgical books, stored in the mosque, were confiscated. Thanks to his students, the imam preserved part of his library. These books lay in the basement of a villager's house until 1947. The executive body of the mosque assigned the imam a monthly salary of 400–500 roubles, but Kh. G. Dautov did not accept the money [9, p. 80].

The Caliph's influence and his popularity among the Muslims of Orenburg were so great that he travelled to different places without a passport. This saint is still well remembered in Batkak, Chishme, Verkhnie Chebenki and many other Tatar villages. Khaliullah the Caliph is known to have visited the cities of Central Asia and Kazakhstan several times [11, p. 186]. It is also known that once Khazrat was arrested. N. Sh. Khusainov wrote that he was in prison in the village of Nikolskoye [11, p. 187].

The Commissioner for Religious Affairs described Kh. G. Dautov as "an educated old man respected by the people."

A group of believers from the village of Tatarskaya Kargala wrote a statement addressed to the Commissioner for Religious Affairs in the Chkalov Region on November 14, 1945. They asked to allocate the building of the former mosque No. 8 for prayer purposes. The believers agreed to tidy up the empty building at their own expense. It is known that 51 people signed this statement [9, p. 79]. Khaliullah Gazizovich Dautov was appointed imam of the mosque. Usually 12–15 believers visited the mosque. On Fridays, the number of believers reached 25–30 people. Since 1950, the number of believers, visiting the mosque on Fridays, increased to 40–45 people, and in 1956 as many as 50 people were registered [9, p. 81].

Khaliullah the Caliph was an excellent doctor. He always helped people for free and saved many from death. Until 1946, he worked in the villages of Kargaly and Verkhnie Chebenki. One of the religious scholars reported that Kh. G. Dautov successfully treated patients suffering from nervous system disorders, headaches and many other diseases. Not only the residents of the Chkalovsky and nearby districts, but even visitors from Moscow came to seek his help. Kh. G. Dautov treated people only with the help of various medicinal plants, from which he prepared medicines. He earned his living by doing this work [9, p. 81].

Archival documents allow us to clarify the imam's attitude to the changes of the Khrushchev

era. After the approval of the Resolution of November 10, 1954, "On mistakes made while carrying out scientific-atheistic propaganda among the population", he expressed his opinion regarding this document: "Comrade Khrushchev is right, you can't laugh at religion... now everyone will know that praying is not prohibited, we don't force young people to pray, we don't prevent them from going to clubs" [9, p. 81].

Khaliullah the Caliph died at the age of 97. On the reverse side of his tombstone it is written: "Sheikh. He will truly remain in the memory of the Tatar people as a spiritual support in harsh times".

During the expedition, a lot of information was found about this outstanding personality. This is what the residents of the village of Kargala say about Kh. G. Dautov.

*Nur Khusainov, the researcher of the regional history:*

"Dautov Khaliullah Gazizullovich, popularly known as Khaliullah the Caliph, was a holy man. He was born in Tatarskaya Kargala, during the war he lived in Verknie Chebenly. His name was known in Orenburg, the Volga-Ural Region and abroad. He could treat cancer, epilepsy and other diseases" [7, p. 92].

In various narrative texts, Khaliullah the Caliph is described as a saint:

"Khaliullah the Caliph is said to have lived in Kargala, he was an educated aman. He looked like Khizr Ilyas (according to the legend a legendary prophet who drank 'living water' from the source of life and gained eternal life; appeared as a beggar, a shepherd or a traveler, giving good advice, wealth or indicating the location of a treasure), and every word he uttered was a shining light. The kings of demons protected him from destructive times. One was white, the other was black" [7, pp. 92–93].

Stylistically, this characteristic is reminiscent of Sufi legends [12, pp. 51–76], [13]. People describe Khaliullah the Caliph as a man equal to a saint. Legends say that Khazrat radiated light.

To prove that their fellow villager had the ability to work miracles, the informants gave various examples. The villagers often said that he miraculously moved in the air:

"People were walking towards Orenburg, they met the Caliph on the way. "Come on, old man, get in the sleigh, you'll get there faster and have rest." He answered: "No, children, I'm walking and I'll get there with God's help." They reached Orenburg and they saw the Caliph walking with two dogs, one was white, the other was black" [7, p. 92].

*Alfiya Saitbattalova*

"Khaliullah the Caliph often went to the cemetery. When the temples were desecrated, the Caliph recognized the graves as the only pure land where worship could be performed. For him, there were no distances or time restrictions. One day, when Khaliullah the Caliph was going to the necropolis, he came across lovers who were kissing. He wailed something, expressing his dissatisfaction and left" [7, p. 97].

"When it was necessary to go to the city, Khaliullah the Caliph did not get into the car, but walked. Come on, Mullah Abiy, get in, we will give you a lift, they told him, but he always refused. Driving into the city, those who were in the car saw that he had already reached the city with God's mercy" [7, p. 97].

"Khaliullah the Caliph was powerful. He healed sick people with herbs. He had two devils. Two demons in the form of dogs guarded him. The Old Man was also a teacher. As one of his students said, he used to beat the fire and wail "don't touch me and I won't touch you". Khaliullah the Caliph slept a lot in the cemetery. When the Bolsheviks chased him in the cemetery, their legs seemed to be drowning in the swamp. And the Caliph fluttered over them" [7, p. 97].

Legends say that Khaliullah the Caliph could find a common language with demons:

"Khaliullah the Caliph was familiar with the demons; he went to visit them. And he hosted them. He asked them not to touch the sons of Adam. The kings of the demons told him: "Don't let them walk on our roads, and if we feel their respect, we we won't touch them" [7, p. 93].

The informants loved to talk about how the aksakal left prison by the will of Allah:

Having been accused of "scaring people and recognizing the power of Allah," he was to be arrested by the Soviet authorities. When they arrived in the morning, they saw that there was no trace of the Caliph. When running after him, they got suffocated in the clouds of dust coming out from under the hooves of the heavenly horses. In the sky, there were only the words: "Allah Akbar." The Caliph was guarded by two dogs, on one side there was a white dog, on the other - a black one" [7, p. 93].

*Damir Musin:*

"Khaliullah the Caliph was taken to prison, but when the guards came in the morning, they saw that the lock had opened by itself" [7, p. 94].

*Mursalimova Madina Saifutdinovna (1928)*:

"Khaliullah the Caliph slept a lot in the cemetery. When the Bolsheviks chased him in the cemetery, their legs seemed to be drowning in the swamp. And the Caliph fluttered over them" [7, p. 97].

"In Siberia, they took him to prison. However, the prison door happened to open all by itself. He was allowed to leave. When he left prison, good horses and sleighs were waiting for him. He probably lived a hundred years"[7, p. 97].

People respected him because he was a skilled doctor:

"People who were close to death came to see him, swarming about his house. He could find a word for everyone, exterminated them with the power of God, gave them the opportunity to atone for their sins. He was a doctor endowed with God's power" [7, p. 93].

*Damir Musin*: "They say there was a Mullah who was a very strong healer. He taught children games" [7, p. 94].

While treating, the doctor held the Koran in his right hand. The informants said that the Caliph used Avicenna's work "The Book of Medicine". He brilliantly mastered the methods of herbal medicine. According to the stories of the fellow villagers who knew him closely, he prepared medicines at clearly defined times of the day. When collecting medicinal plants, he relied on the lunar calendar.

*Mursalimova Madina Saifutdinovna (1928)*:

"He was already old, when we knew him. Khamida's daughter liked him. He moved quickly, like a demon. Every day he used to go out into the field. He used to go down to the shore and during the day he brought small aspen branches, cutting them short. Either its roots were medicinal, or leaves. And he made medicines" [7, p. 94].

Khaliullah the Caliph also practiced spiritual healing. The informants claim that the doctor used hypnosis when treating psychosomatic diseases.

*Gubaidulla Davletyarov (born in 1912)*: "I know the real name of the Caliph. He was much older than me. I know that he was a doctor. To treat stomach diseases, he painted plates with the paint made from saffron flowers. He was an excellent hypnotist. He treated with hypnosis. After the revolution, there was a ban on traditional doctors; they were called charlatans. He was a Mullah in the village of Chebenle. At the end of the war, General Belov was appointed commander-in-chief in Orenburg. His daughter was sick. He travelled a lot around the Moscow Region. No one could cure the girl. Having arrived as a general in the Orenburg-South Ural Military District, he began looking for old doctors. The Russians told him that there was a healer. Someone said that there was one old man who was a mullah. If you went and talked to him, he would help you. Khaliullah the Caliph was the mullah of Kargala and lived in a dugout. They talked with the help of an interpreter: "My grown-up daughter can't walk. Her legs don't function". The Caliph said that he couldn't leave the village and go to treat her: "If you want me to help her, put a bed in this dugout and the girl will be lying here. She will eat what I eat and she will drink what I drink. I will treat her in my own way". After that, he turned to the girl: "You can stretch your legs, why don't you stretch them out". The girl began to stretch out her leg. Everybody was surprised. The general said that he would provide food, if only the Caliph could cure his daughter. In the dugout, the Caliph treated the girl. This probably happened in the fifties. Kawai Abiy, who was the director of the orphanage, told me. Eventually, the girl got back on her feet step by step. When the general arrived, his daughter got into the car. After this, the general built a house for the Caliph" [7, pp. 93–94].

Khaliullah the Caliph treated the sick with spells and with the help of the Koran.

*Aitova Khusniyal Nigmatullovna* (1910):

"Khaliullah the Caliph used Sura Iqra to treat sick people. We had a fellow villager in our neighborhood, Makhmud Abiy, who said that the Caliph had studied Sura Iqra and used it to heal. He treated everyone who was brought to his place. He treated even the most violent ones, having tied their hands. On the forehead of one madman there was the inscription of the CPSU, he threw a handkerchief into the water with the words so that all illnesses would float away along with the scarf, and he recovered" [7, p. 94].

*Agisheva Makhmuza Akhmadullovna* (1925):

"Khaliullah the Caliph was tall, narrow-built, with a long face. 'Stand in line', he would say, 'otherwise there will be no point. You bring your illnesses to me'. I taught at a madrasah for forty years, he was eighty then. He was indignant at an alcoholic who skipped the line. I tried to come in. I was standing on the threshold, I was too shy to come in. 'Come in, girl, I know who's supposed to come in'. I went in, he started reading the spell. He examined my blood vessels, perhaps he learned things from them. I was so exhausted, my ribs were visible, I was afraid to stay at home alone not only at night, but also during the day. He said that he would cure it in two spells and he did" (v.

Isyangildino, the Aleksandrovsky District) [7, p. 97].

It is known that the doctor from Kargala wrote Surahs along the edges of plates.

*Mursalimova Madina Sayfutdinovna* (born 1928):

"He was from Kargala. Maybe he was 100 years old. He died around 1958. He treated people, looked after them. We lived nearby. So many people used to come here! There were a lot of people, like at a crowded station. They lay there for weeks. He didn't ask anything for his service, everyone gave what they could. Sometimes he could read the spell, sometimes he just gave advice. People say that he gave the spelled salt or sugar to eat. Some people used to bring seven new plates, they painted saffron on these seven plates, like ink. At the same time, this paint was written in yellow. After the paints dried on the plates, they were washed, and then they drank this water. The Old Man painted prayers on such plates. I don't know what prayers they were" [7, pp. 94–95].

*Alfiya Saitbattalova* (1967):

"My mother was sick at the age of 13–14. She was unable to walk. My mother's name is Shafieva Fagima Khakimovna, born in 1937. She said that at first, when they began to treat her, her mother carried her in her arms to the Caliph. After a short treatment, she began to walk on her own. She said that the Caliph wrote prayers on a plate. She rinsed this plate and drank water. The Caliph said that this disease was called brucellosis in Russian, and zekhmet in Tatar" [7, p. 97].

The informants reported that the doctor could read the thoughts of others.

*Mursalimova Madina Saшfutdinovna* (born 1928):

"Khaliullah the Caliph, who was simply called Khelle, used to go to the bathhouse of Fakhriyamal apa. When he went into the bathhouse, Fakhriyamal apa thought that he would use up all the water in the bathhouse. She had to carry water with a yoke from the Kargala River and firewood from the forest. She thought that he would not come out soon, but he left the bathhouse fifteen minutes later and said that he did it quickly and did not use up all the water. That's what people say. Once a man went to see him for a treatment. He took gifts with him. He thought that if he gave everything, it would be too much, so he decided to hide part of the gift and gave the rest to the healer. Khelle told him not forget to take what he had hidden under a haystack on his way home. That's how he knew what other people thought" [7, p. 94].

"From his childhood, Khaliullah the Caliph used to walk with a stick. He used to go to the cemetery alone, and stay there all by himself. After someone's funeral, the Caliph went to listen to the speeches. After people left the corpse and walked forty steps away, angels descended to the deceased and began to interrogate his spirit. Khaliullah the Caliph helped to choose the right answers. Some people answered with ease, others with difficultly. Khaliullah the Caliph once heard a moral being read to a very evil man after he had been buried" [7, p. 94].

The residents of Kargala claim that healing abilities ran in the family.

*Maryam Mursalimova*: "The daughter of the Caliph, Hamida, used to predict events from books. Looking very intently at the sky, she asked something, then opened her book and predicted the future. I don't know whether the book was a special one, or whether she herself foreshadowed events. They say that everything came true" [7, p. 94].

"The first time I heard about demons was from Khamida apa. She told about her father. Khamida's father, Khaliullah the Caliph, was a major ishan. The healers came from their family. Her father wanted to transfer his power to Khamida apa, but she refused to accept it. Then her father came in her dream, showed her the toilet and said that he would drown her there if she didn't accept the power. She said she received the gift in her dream. God gave their descendants the power to look after people. She inherited a lot of books and notebooks from her father. If you are bewitched, you need to read a prayer against witchcraft, felek or minas, they need to be read forty-one times during the day. Specific numbers were written in the books. In her dream, she read Alham three times and Colhualla three times. Khamida apa said that you were to take a glass container with water, to say Alham three times and to read Colhualla seven times, to say 'of' (өф) and then to drink this water. Felek, Minas are prayers against witchcraft" [7, p. 96].

*Nurtdin Salimov* (1897): "The world is connected with witchcraft. In Kargala there is an old woman named Khamida. The old woman Khamida made husbands love their wives. Her father was Khaliullah the Caliph. Khaliullah the Chaliph made medicines from herbs. He treated people with herbs and prayers.

Khaliullah the Caliph was very helpful".

*Fatkhrakhman Mursalimov:*

"The people who were going to the mill forgot to take food with them, among them was Mazit

Abyi. On the way, Mazit Abyi met Khaliullah the Caliph. Mazit Abzyi told Khaliullah the Caliph that Faima had prepared food, and he had forgotten to take it. By the time they reached the mill, the Caliph had already brought them food" [7, p. 96].

*Rabiga Musina* (b. 1912): I greeted Khaliullah Khalifa: "Isenmesez" (the literal translation is: "Are you alive?" meaning "Hello"), he said that he was not dead yet. He said when you came in, say either 'How are you', 'Thank God', or 'Alhamdelilla'. He said that this was the wrong greeting used during the Soviet rule. When you said 'isenmesez', it sounded as if you were wondering if I was alive. I was teaching in Sarmanai when my sister wrote to me a letter saying that Khaliullah the Caliph died in 1962.

*Alfiya Saitbattalova: "*When he died, a swan came down to his grave", said his daughter Khamida. "We did not see where it had come from", she said. "It must have been an angel".

## Conclusion

The ethnographic material about Khaliullah the Caliph, collected during the 1991 expedition, is a valuable source for the study of Tatar Sufism. Interesting facts from the real biography of Khaliulla Gazizovich Dautov have been preserved in people's memory. The residents of Kargala describe him as a holy man and a powerful doctor. In legends, Khaliullah the Caliph is on a par with Khizr Ilyas. The main motifs characteristic of Sufi legends are preserved in the stories about Ishan from Kargala (a confessor of Islam, possessing medical skills, Karaites, healing people, etc.). In 2016, Nur Khussein convened a conference of murids (disciples) of the Caliph in Orenburg.

**References**

1. *Pesni Tatarskoi Kargaly: Noty* (2007) [The Songs of Tatar Kargala: Music]. Golos bez soprovozhd. i instrument. melodii (fp.). Sost. i not. transkr., vstup. st. i komment. Ye. M. Smirnovoi; Kazan. gos. konservatoriya (akad.) im. N. G. Zhiganova. 343 p. Kazan'. (In Russian)

2. *Natsional'no-kul'turnoe nasledie: tatary Orenburgskoi oblasti* (2016) [National-Cultural Heritage: Tatars of the Orenburg Region]. 360 p. Kazan', (Iz sokrovishchnitsy nauchnykh ehkspeditsii; kniga trinadtsataya). (In Russian)

3. *Sbornik tatarskogo narodnogo tvorchestva: v 12 t.* (1975–1988) [Collection of Tatar Folk Art: In 12 Volumes]. Kazan', tat. knizhn. izd. (In Russian)

4. Sadykova, Z. R. (1985). *Govory orenburgskikh tatar* [Dialects of the Orenburg Tatars]. 159 p. Kazan', Tatar. kn. izd-vo. (In Russian)

5. Khusainova, A. Ya. (2021). *Tatarskie govory Orenburgskoi oblasti* [Tatar Dialects of the Orenburg Region]. 88 p. Kazan', IYALI. (In Russian)

6. *Atlas tatarskikh narodnykh govorov Srednego Povolzh'ya i Priural'ya* (1989) [Atlas of Tatar Folk Dialects of the Middle Volga and Urals]. Pod red. N. B. Burganovoi, L. T. Makhmutovoi, F. S. Bayazitovoi, D. B. Ramazanovoi, 3. R. Sadykovoi, T. X. Khairutdinovoi. Institut yazyka, literatury i istorii im. G. Ibragimova: v 2-kh t. 240 p. Kazan', Tatprokattekhpribor. (In Russian)

7. Shamsutdinova M. I. (2024). *Yrynbur, Kargaly, bar da timer arbaly* [The Orenburg Region, Kargaly, All Iron Carts]. Lichnyi arkhiv M. I. Shamsutdinovoi. Rukopis', p. 130. (In Tatar)

8. Iskandarov, R., Iskandarov, A. (2005). *Seitov posad: Ocherki po istorii Orenburgskoi (Tatarskoi) Kargaly* [Seitov Posad: Essays on the History of Orenburg (Tatar) Kargaly]. 173 p. Kazan', Tatar. kn. izd-vo. (In Russian)

9. Morgunov, K. A. (2005). *Religioznaya zhizn' v s. Tatarskaya Kargala v poslevoennye desyatiletiya* [Religious Life in the Village of Tatar Kargala in the Post-War Decades]. Iz istorii tatar Orenburzh'ya (k 260-letiyu Tatarskoi Kargaly): sb. materialov nauch.-prakt. konf. Pp. 79–88. Orenburg, izd. tsentr OGAU. (In Russian)

10. Denisov, D. D. (2004). *Usmanov Khairulla Abdrakhmanovich (16.12.1866-27.06.1915)* [Usmanov Khairulla Abdrakhmanovich]. Islam na evropeiskom Vostoke. Ehntsiklopedicheskii slovar'. P. 328. Kazan'. (In Russian)

11. Khusainov, N. F. (2011). *Rol' lichnosti imama Kh. G. Dautova v sokhranenii religii i kul'tury tatar* [The Role of Imam Kh. G. Dautov's Personality in the Preservation of the Tatars' Religion and Culture]. Istoriya i ehtnicheskaya kul'tura tatar Orenburzh'ya (k 105-letiyu so dnya rozhdeniya M. Dzhalilya, 120-letiyu so dnya rozhdeniya M. Faizi i 125-letiyu so dnya rozhdeniya G. Tukaya): mat. mezhregion. nauch.-prakt. konf. Pp. 185–189. Orenburg, izda. tsentr OGAU. (In Russian)

12. Urazmanova, R. K., Gabdrakhmanova, G. F., Zavgarova, F. Kh., Mukhametzyanova, A. R. (2014). *Musul'manskii kul't svyatykh u tatar: obrazy i smysly* [Muslim Cult of Saints among the Tatars: Images and Meanings]. 168 p. Kazan', izd-vo "YAZ". (In Russian)

13. Zakirova, I. G., Fazlutdinov, I. I. (2023). *Legendarnye predaniya o svyatykh v tatarskom fol'klore* [Legendary Tales about Saints in Tatar Folklore]. Filologiya i kul'tura. Philology and Culture. No. 4 (74), pp. 132–140. (In Russian)

# ХАЛЫК ХӘТЕРЕНДӘ ХӘЛИУЛЛА ХӘЛФӘ ОБРАЗЫ (1991 ЕЛДА КАРГАЛЫ АВЫЛЫНА БАРГАН ЭТНОГРАФИК ЭКСПЕДИЦИЯ ЭЗЛӘРЕ БУЕНЧА)

**Мәсгудә Ислам кызы Шәмсетдинова**,
АКШ, Сиэтл,
masguda@mail.ru

Мәкаләдә Татар Каргалысы авылы шәехе Хәлиулла хәлфә турында 1991 елда тупланган экспедиция материаллары анализлана. Хәлиулла Газиз улы Даутов (1872–1960) Каргалының 8 нче мәчетенең тугызынчы имамы булган. Халык хәтерендә ул әүлия карт булып калган. Информантлар аны уникаль дәвалаучы, табиб дип искә ала. Ишанның гадәттән тыш сәләтләргә ия булуы турында сөйлиләр. Архивта сакланган документларда Х.К. Даутовның укымышлы һәм абруйлы карт булуы турында кызыклы фактлар китерелгән.

**Төп төшенчәләр**: Казан консерваториясе, татар халык иҗаты, Оренбург өлкәсе, Каргалы авылы, фәнни экспедиция

## Кереш

1991 елда Казан консерваториясенең бер төркем студентлары (җитәкчесе Мәсгудә Шәмсетдинова) Оренбург өлкәсенең Татар Каргалысында халык музыкаль иҗатын җыеп алып кайта. Экспедиция материалларының бер өлешен Е.М. Смирнова бастырып чыгара [1].

Әлеге өлкә җирлегендә яшәүче халкыбызның авыз иҗаты белән кызыксыну моннан нәкъ 63 ел элек башлана. «Оренбургның татарлар яшәгән районнарына хәзерге Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының иң беренче фольклор экспедициясе 1960 елның май-июнь айларында атаклы фольклорчы галим, филология фәннәре докторы Хәмит Ярми җитәкчелегендә оештырыла. Экспедиция эшендә түбәндәге хезмәткәрләр катнаша: Х. Ярми, Х. Гатина һәм Х. Гарданов. Фольклорчылар ике төркемгә бүленеп, барлыгы 7 районның 11 авылында була (Шарлык районының Мостафа, Сарманай, Яңа Муса авылларында, Александр районының Тукай, Султакай авылларында, Октябрь районының Биккол авылында, Сакмар районының Каргалы авылында, Сарыкташ районының Рәдүт, Әбләз авылларында, Тоз-түбә районының Линевка авылында, Илек районының Озерки авылында). Аларның экспедиция хисапларына күз салсак, түбәндәгеләрне күрәбез: барлыгы 36 әкият, 2530 кыска җыр, 32 сюжетлы җыр, 27 бәет, 215 мәкаль һәм табышмак, 12 халык уены, 64 мәзәк, 28 көй, 18 истәлек язып алынган. Шулай итеп, Институт хезмәткәрләре бер ай эчендә фән өчен бик кыйммәтле халык иҗаты материалларын туплап кайтканнар» [2, б. 3]. Бу төбәктә тупланган материалларның бер өлеше Институт әзерләгән унике томлык татар халык иҗаты җыелмасында (1975–1988) басылган [3].

Оренбург татарларының сөйләшләрен өйрәнер өчен диалектологлар әлеге төбәккә берничә тапкыр экспедициягә чыга. Оренбург татарлары сөйләшләре монографик планда өйрәнелгән [4], [5]. Өлкәдә таралган сөйләшләр «Татар халык сөйләшләренең атласы»нда урын алган [6].

2015 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының бер төркем галимнәре (Комплекслы фәнни экспедиция җитәкчесе – И. Ямалтдинов) Оренбург өлкәсенә халык хәзинәсен бөртекләп җыярга барды. Бу төбәкнең рухи җәүһәрләре тупланган китап дөнья күрде [2, б. 4].

## Хезмәтнең методологик нигезе

Тикшеренү материаллары булып Оренбург өлкәсенең Татар Каргалысы авылы информантларының 1991 елда язылган интервьюлары хезмәт итә [7]. Методологик базаны идеографик (тасвирлау), ретроспектив һәм тарихи чагыштыру ысуллар тәшкил итә.

**Фикер алышу**



*Хәлиулла хәлфә (Хәлиулла Газиз улы Даутов, 1872–1960* [8, б. 57]

Хәлиулла Газиз улы Даутов (1872–1960) – Каргалының 8 нче мәчетенең тугызынчы имамы. Бу күренекле шәхес турында тарихчы К.А. Моргунов үзенең фәнни хезмәтендә шундый мәгълүмат бирә: «Ул 1872 елда Каргалы авылында туган, 1894 елда биредә мәдрәсә тәмамлаган» [9, б. 80]. Каргалының Беренче мәчете мулласы Хәйрулла ишан аның остазы булган [10, б. 374].

1894–1910 елларда Хәлиулла хәлфә башта Курскта, ә аннары Харьковта урнашкан 23 нче пехота Козлов полкында хезмәт итә. Демобилизацияләнгәннән соң, 1910–1920 елларда Х.Г. Даутов Каргалы авылы мәдрәсәсендә укытучы булып хезмәт итә [9, б. 80]. 1930 елда аңа кулга алу куркынычы яный. Тентү вакытында имамның мәчеттә сакланган шәхси документларын, дини китапларын алып китәләр. Шәкертләре ярдәме белән китапханәсенең бер өлеше саклап калынган. Бу китаплар 1947 елга кадәр бер авылдашының идән астында яткан. Мәчетнең башкарма органы имамга ай саен 400-500 сум күләмендә хезмәт хакы билгеләгән булган, ләкин Х.Г. Даутов бу акчадан баш тартан [9, б. 80].

Хәлфәнең абруе һәм аның Оренбург мөселманнары арасында популярлыгы шулкадәр югары булган ки, ул паспортсыз да төрле җирләргә барып йөри алган. Бу әүлиягә тиң шәхесне әле дә Баткак, Чишмә, Югары Чебенле һәм башка күп кенә татар авылларында яхшы хәтерлиләр. Шулай ук Хәлиулла хәлфәнең вакыт-вакыт Урта Азия һәм Казахстан шәһәрләренә дә барып йөргәне билгеле [11, б. 186]. Хәзрәтнең кулга алынуы билгеле. Н.Ш. Хөсәенов аның Никольское авылында төрмәдә утыруы турында яза [11, б. 187].

«Дини культлар эшләре буенча вәкил Х.Г. Даутовны «укымышлы һәм халык арасында абруй казанган карт» дип тасвирлый.

1945 елның 14 ноябрендә Татар Каргалысы авылының дин тотучылар төркеме Чкалов өлкәсенең дини культлар эшләре буенча вәкаләтле вәкиле исеменә гариза яза. Алар элеккеге 8 нче мәчет бинасын гыйбадәт кылу ихтыяҗы өчен бүлеп бирүне сорый. Дин тотучылар буш торган бинаны үз акчаларына тәртипкә китерергә ризалык күрсәтә. Бу гариза астына 51 кеше кул куйганы билгеле [9, б. 79]. Мәчет имамы итеп Хәлиулла Газиз улы Даутов билгеләнә. Гадәттә, мәчеткә 12–15 дин тотучы килеп йөргән. Җомга көннәрендә дин тотучылар саны 25–30 кешегә җиткән. 1950 елдан башлап, җомга көннәрендә мәчеткә йөрүче дин тотучылар саны 40–45 кешегә кадәр арткан, ә 1956 елда хәтта 50 кеше теркәлгән булган [9, б. 81].

Хәлиулла хәлфә бик яхшы табиб булган. Ул кешеләргә һәрвакыт бушлай ярдәм иткән. Күпләрне үлемнән коткарып калган. 1946 елга кадәр Каргалы һәм Югары Чебенле авылларында эшләп йөргән. Дин буенча вәкил үзенең хисабында Х.Г. Даутовның нерв системасы бозылу, баш авырту һәм башка күп кенә авырулардан интегүче авыруларны уңышлы дәвалаучы булуы турында хәбәр итә. Аның янына дәваланырга Чкалов һәм өлкә районнарында яшәүчеләр генә түгел, хәтта Мәскәүдән килүчеләр дә булган. Х.Г. Даутов төрле дару үләннәре ярдәмендә генә дәвалаган, шулардан үзе дарулар әзерләгән. Шул эш белән шөгыльләнеп тапкан акчага тормыш алып барган [9, б. 81].

Архив документлары безгә имамның Хрущёв чорындагы үзгәрешләргә булган мөнәсәбәтен ачыкларга ярдәм итә. 1954 елның 10 ноябрендәге «Халык арасында фәнни-атеистик пропаганда үткәрүдә хаталар турында» карар раслангач, ул вәкилгә бу документка карата үзенең фикерен ирештерә: «Товарищ Хрущёв дөрес әйтә, диннән көләргә ярамый, ... хәзер дога кылу тыелмаганы турында һәркем беләчәк, яшьләрне без мәҗбүр итмибез, аларның клубларга йөрүенә без каршы түгел» [9, б. 81].

Хәлиулла хәлфә 97 яшендә вафат була. Аның кабер ташының кире ягына «Шәйх» дип язылган. Ул чыннан да татар халкының

хәтерендә кискен заманның рухи таянычы булып калачак.

Экспедиция вакытында бу күренекле шәхес турында бик күп мәгълүмат табылды. Х.Г. Даутов турында Каргалы авылы халкы түбәндәгеләрне сөйли.

*Төбәк тарихын өйрәнгән Нур Хөсәенов*:

«Даутов Хәлиулла Газизулла улы, халык телендә Хәлиулла хәлфә, әүлиялəрдән саналган кеше иде. Ул Татар Каргалысында туган, сугыш елларында Үрге Чебенледә яшәгән. Оренбург, Идел-Урал регионында һәм чит өлкәләрдә танылган, бик абруйлы шәхес. Рак, эпилепсия һәм башка авыруларны дәвалаган» [7, б. 92].

Төрле нарратив текстларда Хәлиулла хәлфә әүлия итеп тасвирлана:

«Яшәгән, ди, Каргалыда Хәлиулла хәлфә, укымышлы булган үзе. Хозыр Ильяска охшаган йөзе, нурлар чәчкән әйткән һәрбер сүзе. Саклаган аны вәйран заманнар җеннәр патшалары. Берсе ак, берсе кара булган» [7, б. 92-93].

Стилистик яктан бу характеристика суфиларның риваятьләрен хәтерләтә [12, 51–76], [13]. Хәлиулла хәлфәне халык әүлиягә тиң булган кеше итеп тасвирлый. Риваятьләрдә хәзрәтнең нуры бар, диелә.

Авылдашларының могҗизалар кылу сәләтенә ия булганын раслау өчен информантлар төрле мисаллар китерә. Авыл халкы еш кына аның могҗизалы рәвештә хәрәкәт итүе турында сөйли:

«Бара икән адәм балалары Ырынбурга, Хәллә хәлфә очраган боларга. «Әйдә, бабай, утыр чанага, тизрәк барып җитәрсең, әзрәк ял да итәрсең», – диләр икән. «Юк, балалар, мин үз хәлем белән, Аллаһ куәте белән барам», – дигән бу. Карасалар адәм балалары Ырынбурга җитәрәк, анда Хәллә хәлфә ике эте белән бара, этләрнең берсе ак, берсе кара, ди» [7, б. 92].

*Әлфия Сәетбатталова:*

«Хәлиулла хәлфә еш кына зиратка бара торган булган. Гыйбадәтханәләр мәсхәрәләнгәндә, Хәлиулла хәлфә каберлекләрне гыйбадәт кылырлык бердәнбер пакь җир дип таныган. Аның өчен аралыклар һәм вакыт чикләре булмаган. Бер заман Хәлиулла хәлфә каберлекләр дөньясына очып барганда, юлында үбешеп торган гашыйкларга тап булган. Бәдбәхетләр дип, ризасызлыгын белдереп фырылдап очып киткән, ди ул» [7, б. 97].

«Хәлиулла хәлфә шәһәргә барган вакытта бервакытта да машинага утырмады, җәяү йөрде. Әйдә, мулла абзый, утыр, без сине алып барабыз, дигәндә дә, юк, кирәкми, үзем барам, дип баш тарта. Шәһәргә кергәндә, теге машинадагылар аны күрәләр, ул тагын Алланың рәхмәте белән машинадан алда бара, ди» [7, б. 97].

«Хәлиулла хәлфәнең кодрәте булган. Үлән белән дә өшкергән. Ике җене булган. Ике эт сыйфатында йөргәннәр аны җеннәр саклап. Бабай укыткан да» [7, б. 97].

Риваятьләрдә Хәлиулла хәлфәнең җеннәр белән уртак сүз тапканы да телгә алына:

«Хәллә хәлфә җеннәр белән таныш булган, аларга кунакка йөргән. Һәм аларны үзендә кунак иткән. Алардан ул үтенгән: тимәгез адәм балаларына, кагылмагыз аларга зәхмәтегез белән. Әйткәннәр аңа җен патшалары: йөрмәсеннәр безнең юллардан, аларның хөрмәтен сизсәк, без аларга кагылмабыз» [7, б. 93].

Информантлар шәехнең Алланың кодрәте белән зинданнан үз иреге белән чыгып киткәне турында яратып сөйли:

«Халыкка коткы тарата, Алланың кодрәтен таный, дигән доносларда соң, сәвитләр аны зинданга яба. Иртән килеп карасалар, Хәлиулладан җилләр искән. Артыннан йөгерсәләр, күк юргаларның тояк астыннан чыккан тузан болытларына тончыкканнар сакчылар. Күктә «Аллаһы әкбәр» дигән сүзләр генә сузылып калган. Бер ягында ак эт, бер ягында кара эт саклаган Хәлиулла хәлфәне» [7, б. 93].

*Дамир Мусин:*

«Хәлиулла хәлфәне төрмәләргә япканнар да иртән барып карасалар, йозак үзеннән үзе ачылып, бу чыгып киткән дип сөйлиләр» [7, б. 94].

*Мөрсәлимова Мәдинә Сәйфетдин кызы (1928 елда туган)*:

«Ул Хәлиулла хәлфә каберстанда күп йоклаган. Большевиклар аны зиратта эзәрлекләгәндә, аяклары ябешә икән. Атлый алмаганнар. Хәллә баш очларыннан фырылдап очып йөри торган булган» [7, б. 97].

«Себердә төрмәгә утырткканнар. Кайчан карама, ишеге ачыла, ди, аптырап беткәннәр. Рөхсәт иткәннәр чыгарга. Чыкса төрмәдән, аны көтеп тора икән яхшы атлар, чаналар. Йөз ел яшәгәндер» [7, б. 97].

Халык аны оста табиб булганы өчен хөрмәт иткән:

«Аның ярдәменә мохтаҗ булып, үлемгә хәбәр алган бәндәләр кырмыскадай сырганнар аның яшәгән җирен. Һәрберсенә илаһи сүзен тапкан, Аллаһы Тәгалә кодрәте белән аякка бастырган, чиксезлек алдында гөнаһларын юарга мөмкинлек биргән Алладан зур көчкә ия булган Табиб» [7, б. 93].

*Дамир Мусин*: «Мулла абый барые. Бик көчле лекарь ие. Бала-чагаларга уеннар өйрәтеп китә ие, диләр» [7, б. 94].

Дәвалаганда, табиб уң кулында Коръән тоткан. Информантлар хәлфә Әбүгалисинаның «Тыйп» китабын куллануы турында сөйли. Ул фитотерапия алымнарын искиткеч белеп кулланган. Аны якыннан белгән авылдашлары сөйләве буенча ул тәүлекнең төгәл билгеләнгән вакытында дарулар әзерләгән. Дару үләннәрен җыйганда, ай календарена йөз тоткан.

*Мөрсәлимова Мәдинә Сәйфетдин кызы (1928 елда туган)*:

«Без белә белгәннән карт ые инде. Хәмидә кызына ошаганые. Җен кебек тиз атлап йөрерие. Көн дә тора да яланга чыгып китә. Яр буена төшә дә көн дә вак-вак усакларны алып кайтадырые кыска гына кисеп. Әллә тамырлары дәва булган, әллә яфрагы дәва булган. Дарулар да ясып бирәдерие» [7, б. 94].

Хәлиулла хәлфә рухи дәвалау белән дә шөгыльләнгән. Информантлар психосоматик авыруларны дәвалаганда, табиб гипноз кулланган дип белдерә.

*Гобәйдулла Дәүлетьяров (1912 елда туган)*: «Исемен беләм Хәллә хәлфәнең. Ул миннән күп өлкән кеше. Табиблыгын беләм. Ашказан авыруын дәвалау өчен зәгъфрән чәчәгенең гөленнән чыккан буяу белән тәлинкәләр язган. Ул бик яхшы гипнотизёр булган. Ул гипноз белән лечить иткән кеше. Революциядән соң запрет булды халык табибларына, шарлатаннар, диеп. Хәллә хәлфә Чебенледә мулла була ул. Сугыш беткәчтен, Оренбурга главнокомандующий булып, генерал Белов килә. Аның авыру кызы була. Ул Москвада күп җирләрдә обращать иткән. Кызны һичкем лечить итә алмаган. Оренбургский-Южноуральский военный округка генерал булып килгәч сораша башлаган кемне беләсез иске табиблардан. Урыслар, знахарь, ди. Кемдер әйтә, бар бер бабай, килешә алсагыз. Ул мулла. Барып яхшылап сөйләшсәгез, ул лечить итәр. Хәлиулла хәлфә Каргалының мулласы булып землянкада тора. Тәрҗемәчеләр аша сөйләшә. Менә минем кызым, үсеп җитте, йөри алмый. Аяклары эшләми. Хәлфә әйтә, мин башка җиргә барып лечить итә алмыйм. Әгәр дә теләсәгез, менә шушы землянкада бер караватт куябыз да, кыз шунда ята. Мин ни ашасам, шуны ашый, мин ни эчсәм, шуны эчә. Мин үземчә лечить итеп карыем. Шуннан соң кызга әйтә, синең бит аягың сузыла, ник аягыңны сузмыйсың, ди. Кыз аягын суза башлый. Тегеләр хәйран була. Генерал әйтә, ашау белән тәэмин итәбез, тик лечить ит. Шунда лечить итә Хәлиулла хәлфә. Илленче еллардыр бу хәл. Кавый абый сөйләде миңа, детдомның директоры ые. Фактически, кыз аякка баса постепенно. Генерал килә, кызы машинага чыгып утыра. Шуннан соң генерал Хәллә хәлфәгә йорт салдырып бирә» [7, б. 93-94].

Хәлиулла хәлфә авыруларны өшкергән, Коръән белән дәвалаган.

*Аитова Хөсниямал Нигъмәтулла кызы (1910 елда туган):*

«Хәлиулла хәлфә Икра сүрәсе белән өшкерде. Күрше Мәхмүт бабай барые. Шул әйтәдерие, белеп алган Икра сүрәсен, шуның белән өшкерә дә өшкерә, ди. Кемне алып килсеннәр, шуларны лечить итәдерие. Кулларын бәйләп куеп, дулаган кешеләрне өшкереп терелтәдерие. Бер тиле кешенең маңгаена КПСС дип язылганые. Авыруларың агып китсен дип, кульяулыкларын ташлаган суга. Терелде». [7, б. 94]

*Агишева Мәхмүзә Әхмәдулла кызы (1925 елда туган):*

«Хәлиулла хәлфә озын буйлы, тар гәүдәле, озын яңаклы ине. Чиратта торып керегез, файдасы булмай, ди. Сез бит миңа йөкләп алып киләсез авырлыгыгызны, ди. Мин кырык ел мәдрәсәдә укыттым, ди. Яшем сиксән, ди. Шулай итеп ачулана чиратсыз керергә тырышкан алкоголикны. Басалмаем тупсаны, ул берүзе, оялып тик торам. Кер, кызым, мин кем керәсен белеп утырам, диде. Шуннан кердем. Өшкерде. Тамырлардан тотып карай, кандан белә микән. Чыккан саен җил булып кагынып тора инем. Шул хәтле йөдәгән, кабыргаларым беленеп тора, өйдә берүзем калырга курка инем төнлә генә түгел, көндез дә. Ул әйтте, ике өшкерүдә бетәр. Ике өшкерүдә бетте. *(Александровский районының Исәнгилде авылы)* [7, б. 97].

Каргалы табибының тәлинкә кырыйларына сүрәләр язып дәвалаганы билгеле.

*Мөрсәлимова Мәдинә Сәйфетдин кызы (1928 елда туган)*:

«Үзе Каргалыныкы ие. 100ләргә йетмәдеме икән. 1958 нче йылларда үлде. Өшкерә ие, кешеләрне карыйдырые. Без якын тордык. Шул вакытта монда килгән кеше! Вокзалдагы кебек яталарые. Атналар буе яталарые. Сорап алмасые, кем ни бирә. Өшкерә дә, әйтеп кенә дә чыгара торган булган. Даутов Хәлиулла ые исеме. Өшкереп, йә тоз, йә шикәр ашата диләрие. Тәлинкә яздырып алаларые. Өр-яңа җиде тәлинкә алып киләләрие, шул җиде тәлинкәгә зәгъфран белән суда йебетәләр дә аны кара белән язган кебек язалар. Шуның белән сап-сары итеп язалар. Ул кибә. Шуны чайкатып эчерәләр. Хәлләдән тәлинкә яздырып эчтем, дип сөйли торганые әни. Бабай язып бирә ие. Дога яза ые. Нинди дога, белмим» [7, б. 94-95].

*Әлфия Сәетбатталова (1967 елда туган)*:

«Минем әнием авырган булган 13-14 яшьләрендә. Ул йөри алмас хәлгә килгән булган. Әниемнең исеме Шәфиева Фәгыймә Хәким кызы, 1937 нчы елда туган. Ул сөйли ие, мине башта давалый башлаганда әни күтәреп алып керде Хәлиулла хәлфәгә, диеп. Аннан соң мин үземнең аягым белән бара башладым, ди. Тәлинкәгә дога яза ие, ди. Шуны чайкатып эчәием, ди. Хәлфә әйткән, бу авыру русча әйткәндә, бруцеллез, татарча әйткәндә, зәхмәт дигән» [7, б. 97].

Информантлар хәбәр иткәнчә, табиб кешеләрнең уйларын да белеп торган.

*Мөрсәлимова Мәдинә Сәйфетдин кызы (1928 елда туган)*:

«Мынчачы Фәхриямал апага мынчага барган Хәлиулла хәлфә, аны Хәллә дип кенә йөртәләрие. Шуннан шул мынчадан чыккан Хәлиулла хәлфә, ул апа уйлый икән эченнән, инде чыкты инде бу, бөтен суны бетерер инде. Суны көянтәләп ташый бит, утынны урманнан ташый. Каргалы елгасыннан су ташый. Тиз чыкмас инде бу дип уйлаган. Теге унбиш минутта чыккан да, менә тиз чыктым, суыңны да бетермәдем, дигән. Тегенең уйлаган уен белеп торган. Шулай итеп сөйлиләрие кешеләр. Шуннан Хәллә Чебеннедә дә торган бит ул. Шул вакытта берәү барган лечениега аңа. Алып барган әйберләр падарыкка. И, бөтенесен дә бирсәм моның, күп була инде. Яшереп калдырган. Барган, каралган, теге әйберне биргән. Кайтканда теге печән төбендәгесен онытма алырга, дип әйтә, ди. Шулай итеп кешенең уен белә торган булган» [7, б. 94].

«Хәлиулла хәлфә кечкенәдән таяк белән йөрегән. Зиратка берүзе менгән, шунда калган берүзе. Кешене күмеп китәләр бит. Хәлиулла хәлфә зиратка барып, мәетне тыңлаган. Кешеләр мәетне калдырып, кырык адым китәләр дә, фирештәләр сорау алырга киләләр мәетнең рухыннан. Хәлиулла хәлфә ярдәм иткән нинди сүзләр әйтергә. Менә шундый кеше бик җиңел җавап бирде, кайберләре бик авыр. Хәлиулла хәлфә ишеткән, бик әшәке кеше кабергә күмелгәч иман китергән. Шуны Хәлиулла хәлфә ишеткән» [7, б. 94].

Каргалылар дәвалау сәләте нәсел бүләге дип белдерә.

*Мәрьям Мөрсәлимова*: «Хәлиулла хәлфәнең кызы Хәмидә китап ачадырые. Бик бирелеп, күккә карап, бик внимательно сорый ые. Шуннан китапны ача да сорый. Нинди китапмы, шуннан туры китереп, үзе юраганмы. Дөрес килә диләрие» [7, б. 94].

«Җеннәр турында беренче ишеттем Хәмидә ападан. Сөйли ие әтисе турында. Хәмидә апаның әтисе Хәлиулла хәлфә ул бик зур ишан булган. Өшкерүчеләр аларның нәселеннән килә. Әтисе күчерәсе килгән ул өшкерү көчен Хәмидә апага, ал, кызым, юк, алмыйм, әти, дигән Хәмидә апа. Төшемә әти килде, менә бәдрәф, әйтә, батырам шунда, алмасаң. Төшемдә алдым, ди. Аларның нәселенә Аллаһы Тәгалә биргән көч кешеләрне карарга. Хәмидә апа китап ачадырые. Коръәннең тәфсире. Әтисеннән аңа калды күп китаплар, дәфтәрләр. Сихыр тисә, сихыр догасын – фәләк, миннәсне кырык бер мәртәбә укырга кирәк көн буена. Китапларында язылган, үзләренең цифрлары була. Төш күргән вакытта өч мәртәбә Әлхәмны, өч мәртәбә Колхуалланы укырга. Хәмидә апа әйтте, ал пыяла су белән, өч мәртәбә Әлхәмне әйт, җиде мәртәбә Колхуалланы укы да, өф әйт, аннан соң эч ул суны. Фәләк, Миннәс инде сихырдан догалар» [7, б. 96].

*Нуретдин Сәлимов (1897 елда туган)*: «Сихыр белән бәйләнгән дөнья. Каргалыда берәү бар, Хәмидә дигән карчык. Каргалы хатыннарының ирләрен яраттырып торган Хәмидә карчык. Әтисе Хәлиулла хәлфә. Хәлиулла хәлфә өшкерә ие, үләннән ясап бирә ие даруларны. Үлән белән, дога белән өшкерә ие» [7, б. 96].

Хәлиулла хәлфә бик ярдәмчел булган.

*Фәтхерахман Мөрсәлимов*:

«Тегермәнгә китеп баручы кешеләр ашарларына онытканнар, араларында Мәҗит абый бар инде. Шул Мәҗит абый Хәлиулла хәлфәне очрата Майорда. Хәлиулла хәлфәгә Мәҗит абзый әйткән, Фәимә ашарга

әзерләгәние, онытып калдырганмын, дигән. Бераз баруларына йетеп Хәлиулла хәлфә китереп биргән теге ризыкны» [7, б. 96].

Риваятьләрдә үлеме турында да кызыклы мәгълүмат бар.

*Рәбига Мусина (1912 елда туган)*: «Мин әйттем Хәлиулла хәлфәгә, исәнмесез, дидем, әле мин үлмәгән, диде. Кергәчтен, бабай нихәлсез, Аллага шөкер йә әлхәмделиллаһ дип әйт, диде. Совет заманында чыккан хәл диде дә авызны япты да куйды. Исәнмесез дигәчтен, әле сез үлмәгәнсез икән дигән мәгънәдә, диде. Мин Сарманайда укытадыр идем, сеңлем хат язды, 1962дә микән, Хәлиулла хәлфә үлде, дип» [7, б. 96].

*Әлфия Сәетбатталова:*

«Ул үлгәндә, бер аккош каберенә кереп китте, диде кызы Хәмидә апа. Без күрмәдек аны, каян килеп чыкканын, диде. Фирештә булгандыр» [7, б. 96].

## Нәтиҗәләр

1991 елгы экспедиция вакытында Хәлиулла хәлфә турында җыелган этнографик материал татар суфичылыгын өйрәнүнең кыйммәтле чыганагы булып тора. Халык хәтерендә Хәлиулла Газиз улы Даутовның реаль биографиясеннән кызыклы фактлар сакланган. Каргалылар аны әүлиягә тиң шәхес итеп тасвирлый, көчле табиб булганын исбатлап сөйли. Риваятьләрдә Хәлиулла хәлфәне Хозыр Ильяска тиң шәхес итеп сурәтлиләр. Суфилар турында риваятьләргә хас төп мотивлар Каргалы шәехе турында булган хикәятләрдә саклана (Исламны таратучы, табиб осталыгы, кирәмәтләр, саваплы эшләр һ.б.). 2016 елда Нур Хөсәенов Оренбургта Хәлиулла хәлфә мөридләрен конференциягә җыйган.

**Әдәбият**


1. Песни Татарской Каргалы: [Ноты]: голос без сопровожд. и инструмент. мелодии (фп.) / сост. и ред. нот. транскр., вступ. ст. и коммент. Е.М. Смирновой; Казан. гос. консерватория (акад.) им. Н. Г. Жиганова. Казань, 2007. 343 с.
2. Милли-мәдәни мирасыбыз: Оренбург өлкәсе татарлары. Казан, 2016. 360 б. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән; унөченче китап).
3. Татар халык иҗаты җыелмасы: 12 т. Казан: Татар кит. нәшр. 1975–1988.
4. Садыкова З.Р. Говоры оренбургских татар. Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. 159 с.
5. Хусаинова А.Я. Татарские говоры Оренбургской области Казань: ИЯЛИ, 2021. 88 с.
6. Атлас татарских народных говоров Среднего Поволжья и Приуралья / Под ред. Н.Б. Бургановой, Л.Т. Махмутовой, Ф.С. Баязитовой, Д.Б. Рамазановой, З.Р. Садыковой, Т.Х. Хайрутдиновой / Институт языка, литературы и истории им. Г.Ибрагимова: в 2-х т. Казань: Татпрокаттехприбор, 1989. 240 с.
7. Шәмсетдинова М.И. Ырынбур, Каргалы, бар да тимер арбалы // М.И. Шәмсетдинова шәхси архивы. Кульъязма. 2024. 130 б.
8. Искандаров Р., Искандаров А. Сеитов посад: Очерки по истории Оренбургской (Татарской) Каргалы. Казань: Татар. кн. изд-во, 2005, 173 б.
9. Моргунов К. А. Религиозная жизнь в с. Татарская Каргала в послевоенные десятилетия // Из истории татар Оренбуржья (к 260-летию Татарской Каргалы): сб. материалов науч.-практ. конф. – Оренбург: Изд. центр ОГАУ, 2005. С. 79–88.
10. Денисов Д.Д. Усманов Хайрулла Абдрахманович (16.12.1866-27.06.1915) // Ислам на европейском Востоке. Энциклопедический словарь. Казань, 2004. С. 328.
11. Хусаинов Н. Ф. Роль личности имама Х. Г. Даутова в сохранении религии и культуры татар // История и этническая культура татар Оренбуржья (к 105-летию со дня рождения М. Джалиля, 120-летию со дня рождения М. Файзи и 125-летию со дня рождения Г. Тукая): мат. межрегион. науч.-практ. конф. Оренбург: Изда. центр ОГАУ, 2011. С. 185–189.
12. Уразманова Р.К., Габдрахманова Г.Ф., Завгарова Ф.Х., Мухаметзянова А.Р. Мусульманский культ святых у татар: образы и смыслы. Казань: Изд-во «ЯЗ», 2014. 168 с.
13. Закирова И.Г., Фазлутдинов И.И. Легендарные предания о святых в татарском фольклоре // Филология и культура. Philology and Culture. 2023. №4 (74). С. 132–140.

# ОБРАЗ ХАЛИУЛЛЫ ХАЛЬФЫ В НАРОДНОЙ ПАМЯТИ (ПО СЛЕДАМ ЭТНОГРАФИЧЕСКОЙ ЭКСПЕДИЦИИ В ТАТАРСКИЕ КАРГАЛЫ В 1991 Г.)

**Масгуда Исламовна Шамсутдинова,**
США, Сиэтл,
masguda@mail.ru.

В статье анализируются экспедиционные материалы 1991 г. о шейхе Халиулле хальфе из деревни Татарские Каргалы. Халиулла Газизович Даутов (1872–1960) был девятым имамом 8-й мечети. В памяти народной аксакала возводят в ранг аулиа. Информанты приводят факты, свидетельствующие о том, что он был уникальным знахарем, народным целителем. Согласно архивным документам, Х. К. Даутов был весьма образованным человеком, известным далеко за пределами Оренбургской области. К нему приезжали лечиться из столицы и заграницы.

**Ключевые слова**: Казанская консерватория, татарское народное творчество, Оренбургская область, деревня Каргалы, научная экспедиция